КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 28 март г.Казань № 193

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында «Яр Чаллы – Водозабор», 1+462 км – 2+102 км төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының VII бүлегенең 49 статьясы, $VII^1$ бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Татарстанның юл-транспорт идарәсе) Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында «Яр Чаллы – Водозабор», 1+462 км – 2+102 км төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен физик затлар (алга таба – алына торган җир кишәрлекләре милекчеләре) милкендә булган, 1 нче кушымтада күрсәтелгән, 58 324 кв.метр гомуми мәйданлы җир кишәрлекләреннән барлыкка килә торган 10 935 кв.метр гомуми мәйданлы җир кишәрлекләрен (алга таба – алына торган җир кишәрлекләре) алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Алына торган җир кишәрлекләрендә урнашкан һәм 2 нче кушымтада күрсәтелгән күчемсез мөлкәт объектлары алынмый дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районындагы Әҗмәкәй авыл җирлегенең муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка белдерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен алына торган җир кишәрлекләре милекчеләренә, «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне;

алына торган җир кишәрлекләре өчен түләү күләмен билгеләгәннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында килешүләр (алга таба – килешүләр) әзерләүне һәм аларны алына торган җир кишәрлекләре милекчеләренә җибәрүне;

килешүләр төзүне;

алына торган җир кишәрлекләре өчен акча түләүне;

алына торган җир кишәрлекләренә Татарстан Республикасы милке хокукын дәүләт теркәвенә алуны;

алына торган җир кишәрлекләре милекчеләре тарафыннан имза куелган килешүләр законнар белән билгеләнгән срокта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъва бирүне.

4. Татарстанның юл-транспорт идарәсенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында «Яр Чаллы – Водозабор», 1+462 км – 2+102 км төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү» объекты буенча территорияне планлаштыру проектын һәм межалау проектын раслау турында» 2022 ел, 29 июнь, 1900 нче карары белән расланган территорияне планлаштыру проекты һәм межалау проекты нигезендә 1 нче кушымтада күрсәтелгән җир кишәрлекләренә карата кадастр эшләрен үткәрүне;

алына торган җир кишәрлекләре өчен акча түләү күләмен билгеләүне.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 28 март, 193 нче
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен алынырга тиешле
җир кишәрлекләре исемлеге

| Т/с | Кадастр номеры | Урнашу урыны | Җир кишәр-легенең гомуми мәйданы, кв.метр | Алына торган мәйдан, кв.метр | Милекчесе |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1. | 16:39:021201:4748 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Әҗмәкәй авыл җирлеге | 7 041 | 563 | Кобзев Андрей Сергеевич |
| 2. | 16:39:021101:2135 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Әҗмәкәй авыл җирлеге | 2 000 | 36 | Моратова Лилия Рафинат кызы |
| 3. | 16:39:021101:2136 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Әҗмәкәй авыл җирлеге | 2 500 | 59 | Гыйльфанов Ленар Шәмсемөхәммәт улы |
| 4. | 16:39:021101:2137 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Әҗмәкәй авыл җирлеге | 2 500 | 46 | Овчинникова Аляна Альфировна |
| 5. | 16:39:021101:1948 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Әҗмәкәй авыл җирлеге | 3 000 | 62 | Галиев Илнур Нурсил улы |
| 6. | 16:39:021101:1947 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Әҗмәкәй авыл җирлеге | 3 000 | 153 | Галиев Илнур Нурсил улы |
| 7. | 16:39:021101:1911 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Әҗмәкәй авыл җирлеге | 6 000 | 890 | Осипов Николай Михайлович |
| 8. | 16:39:021101:1764 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Әҗмәкәй авыл җирлеге | 8 000 | 3 124 | Осипов Николай Михайлович |
| 9. | 16:39:021001:405 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Әҗмәкәй авыл җирлеге | 2 444 | 731 | Ямаев Таһир Вәли улы |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| 10. | 16:39:021001:407 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Әҗмәкәй авыл җирлеге | 2 159 | 291 | Ямаев Таһир Вәли улы |
| 11. | 16:39:021001:496 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Әҗмәкәй авыл җирлеге | 1 645 | 773 | Вәлиуллина Чулпан Салават кызы |
| 12. | 16:39:021001:592 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Әҗмәкәй авыл җирлеге | 14 258 | 2 831 | Фәттахова Алсу Фәссах кызы |
| 13. | 16:39:021001:461 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Әҗмәкәй авыл җирлеге | 1 007 | 735 | Дәүлиев Рөстәм Рим улы |
| 14. | 16:39:021001:593 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Әҗмәкәй авыл җирлеге | 1 010 | 342 | Дәүлиев Рөстәм Рим улы |
| 15. | 16:39:021001:460 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Әҗмәкәй авыл җирлеге | 700 | 261 | Мильчакова Марина Ивановна |
| 16. | 16:39:021001:890 | Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Әҗмәкәй авыл җирлеге | 1 060 | 38 | Әхтәмов Нәсим Әхтәм улы |
| Барлыгы | | | 58 324 | 10 935 | |

___

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 28 март, 193 нче
карарына 2 нче кушымта

Алына торган җир кишәрлекләрендә урнашкан
күчемсез мөлкәт объектлары
исемлеге

| Җир кишәрлегенең кадастр номеры | Күчемсез мөлкәт объектының кадастр номеры | Күчемсез мөлкәт объекты исеме |
|---|---|---|
| 16:39:021001:405 | 16:00:000000:897 | «ВЛ-110 кВ п/ст. Заводская – водозабор» |
| | 16:39:000000:6417 | «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Әҗмәкәй авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен төзү» |
| 16:39:021001:461<br>16:39:021001:592<br>16:39:021001:593 | 16:00:000000:1035 | «Яр Чаллы шәһәренең Подсолнухи поселогына суүткәргеч төзү» |
| 16:39:021001:890 | 16:00:000000:1035 | «Яр Чаллы шәһәренең Подсолнухи поселогына суүткәргеч төзү» |
| | 16:39:021001:623 | «Склад урыннары белән кибет» |
| 16:39:021101:1764 | 16:00:000000:897 | «ВЛ-110 кВ п/ст. Заводская – водозабор» |
| | 16:00:000000:68319 | «ВЛ-110 кВ Заводская – КНС 7» |
| | 16:39:021101:2438 | «Хуҗалык блогы» |
| | 16:39:021101:2462 | «Хуҗалык блогы» |
| 16:39:021101:1911<br>16:39:021101:1947<br>16:39:021101:1948<br>16:39:021101:2135 | 16:00:000000:897<br>16:00:000000:68319 | «ВЛ-110 кВ п/ст. Заводская – водозабор»<br>«ВЛ-110 кВ Заводская – КНС 7» |
| 16:39:021101:2136<br>16:39:021101:2137 | 16:00:000000:897 | «ВЛ-110 кВ п/ст. Заводская – водозабор» |
| 16:39:021201:4748 | 16:00:000000:900 | «ВЛ-110 кВ ТЭЦ – Водозабор с отпайкой на СОВ» |